


Чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * СЕНТЯБРЬ * 2016 * КАЗАН

15

Сергей АНДРИАНОВ



АННАН-МОННАН
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Электрон сайлаулар үткәрү варианты карала. Социаль челтәргә кандидатларның фоторәсемнәре эленә. Кем күпме лайклар җыя — шул җиңә.
- ИГИЛ Казан юлларының чокырчакыры булуын һәм яңгыр суларын агызып җибәрә торган люк каплавычларын урлауны үз өстенә алган.
- Трамп, Олимпия уеннарын бары тик Мексика уенчыларының колга белән нихәтле биек сикерерләр икән дип кенә каравын таныды.
- Рио-де-Жанейродагы бер хулиганны, Олимпиадада дзюдо буенча бакыр медаль алган көрәшчене кыйнаганы һәм пляжда әйберләрен урлаганы өчен Бразилиянең җыелма командасы составына алганнар.
- Кокаин белән наркополицияләр агуланган наркодилерны тоткарлаганнар.
- Ел саен линолеум өчен акча җыймас өчен, 5 нче "А" класс ата-аналары класстагы идәнгә асфальт җәяргә булганнар.
- Динчеләр бер фикергә килгәннәр — хатынсыз ир — ярты иблис.
- Гаишник, тизлекне арттырганга түләнергә тиешле штраф планын үтәү өчен, радарын күтәреп, машиналарга каршы йөгереп йөргән.
- ИКЕА буенча адашып йөрү – скандинав йөреше итеп танылган.
- Шәһәр тирәсендәге урманда бер төркем кәрзинле явызлар, ыргыйларча, ак гөмбәләр гаиләсен кисеп чыкканнар.
- Серле рәвештә циркның еллык отчеты юкка чыгуы – әлеге елның иң көчле фокусы дип танылган.
- Акыллы су краны (смеситель) уйлап табылган. Кайнар су бирелми башласа, бу эшкә җаваплы түрәләрнең фамилияләрен әйтеп бирә икән. Болай иткәндә, гаеплеләргә каршы каргыш төгәл барып ирешә.
- Ел эчемлеге итеп дуләнә (боярышник) танылган. Белгечләр, аны эчкәннән соң, җанга наз тойгысы, авызда сизелерлек спирт тәме калуына игътибар биргәннәр.
- Үзен җирләүнең күпмегә төшәчәген белгәч, мәет табутында йөзтүбән әйләнеп яткан.
- Покемоннар бандасы ике уенчыны тоткан.





ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Телевидениедәге реклама безнең яшүсмерләрне – сыра, ә балаларны кока-кола һәм башка татлы эчемлекләр колына әйләндерде. Еш кына күрергә туры килә – урам буйлап кулына кола тоткан туп кебек түгәрәк бала бара. Ә янәшәсендә, «кабартма»сына сокланып, әнисе бара. Ул бу эчемлектә шикәрнең микъдары дистәләгән тапкыр нормадан артыграк икәнен белми микәнни? Аннан соң симерү, шикәр авыруы дип йөрибез...

Л. ВӘЛИЕВА

ТҮБӘН КАМА

– «Балалар кокаколизмы» эпидемиясе игълан итәргә вакыттыр, күрәсең, – диде Шомбай ага, укучының хатын укып чыккач.



Илдус АЗИМОВ





Хөрмәтле сатып алучылар! Ишекләрне ябып йөрегез. Салкынны саклагыз!

Кафега үз аракың һәм кабымлыгың белән керү тыела. Вакытлыча уңайсызлык өчен гафу итегез.

Хөрмәтле ханымнар! Сөяркәләрне җирле кешеләр арасында табарга тырышыгыз. Машина куярга үзебезгә дә урын җитми.

Тәүлек буе эшлибез. 7 дән 7 гә кадәр.

Игътибар! Иртәгә яңа җитештерелгән продуктлар китереләчәк. Администрация.

Хөрмәтле сатып алучылар! Сатучылар йөк ташучылары белән бергә башка урынга күчеп киттеләр.

(белдерүләр)

ЧАЯННЫҢ АЛТЫН САНДЫГЫННАН

Әхмәт ИСХАК

БӘЛӘКӘЙ МӘСӘЛЛӘР


Куян белән арыслан
Куян,
Каушап куркуыннан,
Куйган Арысланга ялгышып мат.
Һәм иткән ант –
Шахмат уйнамаска икенче кат.

Геометрик көнләү
Туры сызык
Түгәрәк сызыктан көнли:
Яшерә, имеш,
ул очын шулкадәр нык, –
Кая яшергәнен һичкем белми!

Ялагай керпе
Борчымасын өчен түрәләрен,
Керпе, парикмахерга кереп,
Тәнендәге барлык инәләрен
Чыккан бөдрәләттереп.

Пәрдә
– Артымда ни барын
Күрсәләр әгәр дә,
Нишләрмен мин? – диеп
Калтырый, ди, Пәрдә.

Ринат АБЗАЛОВ





Алтын унитазлар

Иң гади канализация кулланучылар белән көрәштә коммуналь хезмәт хуҗалары кулында һаман дәһшәтлерәк коралга әверелә бара. Кайберләре клиентларны йөгәндә тотар өчен махсус җайланма – “Терминатор” дигән куркыныч исем белән аталган томалагыч-бөке файдалана башладылар.

Ә менә Казанның МУП “Водоканал” белгечләре бернинди җайланмасыз-нисез теләсә кемнең котын алалар. Мәсәлән, медицина университеты клиникасына норматив буенча 1,6 миллион сумлык счёт юллаганнар. Югыйсә оешмада су исәпләү приборы булган, һәм бернинди бурычы булмаган. Шуңа карамастан, клиника таләпкә буйсынып, күрсәтелгән сумманы түләүне кирәк тапкан. Бәлки, курыкканнардыр: кем белә бит, йә “Водоканал” әһелләре тагын да куркынычрак корал кулланыр…

Татарстанның Хисап палатасы тикшерү җибәрмәсә, медикларның тагын күпме башларын катырыр иделәр икән. Бары шуннан соң гына клиникага җибәрелгән счёт гамәлдән чыгарылган…

Боровое Матюшино бистәсендә урнашкан Республика неврология үзәгенең филиалында да ревизорлар кызыклы хәлгә юлыкканнар. Анда агынтылар чисталыгы өчен көрәштә конкуренция булмау сәбәпле, җирле кешеләргә ООО “Санта-2” дип аталган оешма белән генә эш итәргә туры килә. Хезмәт күрсәтү бәяләрен компания үзе билгели. Мәсәлән, 2014 елда үзәк филиалында бер кубометр агынты чыгаруның бәясе 834 сум булган. Чагыштырып карыйк: янәшәдә генә урнашкан Лаеш үзәк район хастаханәсенә бу 34 сумга төшә. Ә хастаханәнең Казандагы бүлеге өчен бары тик 13,5 сум тора. Шулай итеп, соңгы дүрт ел ярым эчендә “Санта-2”гә миллион сумга якын өстәмә акча түләнгән. Ни сәбәпле Матюшино унитазлары алтын бәясенә күтәрелгәндер – бу әлегә кадәр сер булып кала…

Хәзер филиалда түземсезлек белән яңа елны көтәләр. Бәлки, канализация монополисты үзен тыйнаграк тота башлар, һәм унитаз “агымсу”лары болай ук кыйммәткә төшми башлар?

Тимур ШАТОВ

ТИЛЕфоннар!

Михаил ЛАРИЧЕВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Алексей БУЛАТОВ







• • •

– Рәсәйдәге нефть – Гарәп Әмирлекләрендәге хәтле, ә кешеләребез ярлырак яши.

– Ә Әмирлекнең халкы күпме?

– Дүрт миллион.

– Нигә алай икән? Әмирлектәге хәтле генә дүрт миллион халык бездә дә яши бит инде.

• • •

– Исәнмесез, сезгә ФСБдан шалтыраталар.

– Мин беләм.

– Каян?

– Сез миңа эшләми торган телефонына шалтыратасыз бит.

• • •

Спортта допинг кулланганлыктан ярышларга катнаштырмау – бу әле башлангычы гына. Тиздән сәясәттә дә, фәндә дә һәм балетта да допингка тикшерүләр башланачак...

• • •

Бер бабай лотереяга миллион откан. Журналистлар моның хисләре белән бүлешүен сорыйлар.

– Мин шулхәтле шат, ниһаять минем яңадан зур һәм мине өзелеп сөюче гаиләм барлыкка килде, – дип җавап бирә ялгызлыктан гаҗиз булган картлач.

• • •

"Сезнең кыңгырау бирүегез безнең өчен бик әһәмиятле!" – дип елмаешылар тәнәфескә чыгучы укучылар җыештыручы Сания апаларына.

• • •

Хәзер Рәсәй спортчыларына һәрвакыт мега-контроль ясап торачаклар. Ничекме? Йөгерүчеләр 100 метрның һәр 10 метры саен банкага пес итәргә тиеш булачаклар...

• • •

Репетициядә оркестр дирижеры барабанчылар уенынннан канәгать түгел:

– Әгәр музыкант башка бернәрсәдә дә уйный белмәсә, аңа ике таяк бирәләр, һәм ул барабанчы булып китә, – ди ул.

Оркестрда пышылдашу:

– Әгәр дә инде барабанда да уйный белмәсә, аның бер таягын алалар, һәм ул дирижер була.





“ЗӨБӘРҖӘТ САТУЧЫЛАР”

Казанлылар шәһәрнең Юдино бистәсендә урнашкан Зөбәрҗәт (Изумрудное) күле янындагы түләүсез пляж һәм парковка өчен биш ел буе акча түләп килгәннәр. Күпсанлы шикаятьләргә карамастан, законсыз куелган шлагбаум белән прокуратура әле күптән түгел генә кызыксына башлаган. Тикшерү вакытында эшмәкәрләрнең күл янында кафе тотарга гына рөхсәтләре булган. Аңа да карамастан, малкуарлар төп табышны су коенучылардан алып килгәннәр —көненә уртача 50 мең сум! Җинаять эше кузгатылган очракта “һава сатучы”ларга... 300 мең сум штраф яный.

СЮЖЕТТАН ТАЙПЫЛУ

Атаклы Павел Иванович Чичиков кәгазьдә тере булып саналган “үле җаннар” сатып алган. Омск шәһәрендә яшәүче бер ханым Гоголь сюжетын кирегә әйләндерергә булган: документлар буенча ул вафат булып саналган, ә чынлыкта исә сау-сәламәт булып яшәп яткан. Ипотека буенча фатир сатып алып, ул гомерен страховкалаган. Ә аннан соң... тормыш белән хушлашырга булган. Ялган медицина документлары ясап, “Чичиков ханым” үзенең теге дөньяга китүе турында таныклык юнәткән. Бу кәгазьләр буенча ул страхование компаниясеннән 600 мең сум алган. Тик вакыйгалар Гоголь сюжетыннан читкә тайпылган: әгәр язучының персонажы иркен Рәсәй киңлекләрендә югалган булса, бу “тере мәет”кә суд якындагы ике ел дәвамына башка яшәү урыны тәкъдим иткән.

КҮРЕНСӘ ГЕНӘ ОЯТ

Кытайда бурычлары булган компанияләрнең хуҗалары белән көрәшүнең гадәти булмаган ысулын уйлап тапканнар. Аларның исемнәре, адреслары һәм башка мәгълүматлары, суд карары буенча, Шанхай шәһәренең вокзалларындагы зур стенд-экраннарда күрсәтелгән. Хөкемдарлар фикеренчә, бу ысул банк счётларына “йозак салу”га караганда, яхшырак нәтиҗә бирә, чөнки Конфуций илендә кешене оятка калдыру иң үтемле корал булып санала. Һәм чынлап та, экранда булып чыкканнарның барысы да тиз арада бурычларын кайтарганнар. Гаҗәп, “Алдаудан соң оят бар” мәкале барлыкка килгән илебездә бу ысул нигә эшләми икән?

Алексей БУЛАТОВ



Александр АЛЁШИН





«ЭТ ИЯРТКӘН ХАНЫМ»

Чехов персонажыннан аермалы буларак, Чаллыда яшәүче М. ханым курорт гыйшык-мыйшыклары белән мавыкмаган. Яз көне ул Интернетта хаски токымлы көчек сату турында белдерү биргән һәм аның өчен 12 мең сум акча алган. Тик сатып алучы көчекне күрү бәхетенә ирешә алмый – ул виртуаль дөньяда гына яшәгән булып чыга. М.ны хөкемгә тарталар, һәм шунда ук амнистия буенча азат итәләр.

Җиңелчә курыкканнан соң, аңына килеп, ул иске кәсебе белән шөгыльләнүен дәвам итә. «Вельш корги пемброк» дигән экзотик токым исеме табып, тагын белдерү бирә һәм 10 мең сумны кесәсенә сала. Бу юлы да этнең әсәре дә юк. Курыкмас ханымны тагын суд көтә. Үзе сайлап алган «эт тормышы» бит инде бу...

Мәрьям ХИСАМОВА

Валерий ТАРАСЕНКО



Валерий ТАРАСЕНКО



ТОКЫМЫ КОРГЫРЫ

Волгоград өлкәсенең урманнарында коткаручылар ике югалган кешене эзлиләр. Ир-егетләр адашкан тёщаларын эзләргә дип чыкканнар. Хатыннар урманнан үзләре чыкканнар, ә менә кияүләрне эзләү дәвам итә.

• • •

Михаил Задорновның америкалыларның мокытлыгы турындагы сүзләре һаман яңа раслау таба тора. Берзаман Bank of America бинасына талаучы килеп кергән. Бланкка үзенең таләпләрен язып, чиратка баскан. Чиратта түземлеге бетеп, ул башка банкка киткән. Андагы оператор, язуның башка банк бланкында язылган булуына сылтап, аны кабул итүдән баш тарткан. Талаучы яңа бланк тутырган арада, банк хезмәткәрләре полиция чакырганнар.

• • •

Кояшлы Краснодарда яшәүче өлкән яшьләрдәге бер ханым... мэрия бинасы каршында үскән илле роза куагын казып алан. Тик аңа качарга бирмәгәннәр: янәшәдәге йортларның берсендә яшәүчеләрнең берсе, сәерсенеп, полициягә шалтыраткан. Бүлекчәдә, сорау алганда, затлы чәчәкләрне үзенең дачасын яшелләндер өчен алганлыгын аңлаткан.

• • •

Смоленск шәһәрендә бер менеджер, эшкә чыкмаганлыгын аңлатыр өчен, тикшерү комитетына шаһит буларак чыкырылуы турында ялган повестка ясаган. Фирма җитәкчелеге, тиешле оешмага шалтыратып, хезмәткәренең намуслылыгын тикшерергә булган. Ялган фаш ителгән, ә алдакчы хезмәткәр хокук саклау органнарында чынлап җавап тотарга мәҗбүр булган.



Антон МАКУНИ



Кичә миңа бер ир керде — порошок кирәкмиме, тараканнарга каршы шәп дару, ди. Сатып алдым. Сиптем. Киресенчә килеп чыкты — тараканнар артты, тычканнар күбәйде. Аларның бит миндә гомердә булганнары юк иде!

Мин ул даруны чыгарып ташлармын дигән идем инде, туктап калдым. Әрәм булмасын, дип балкондагы укропны эшкәртергә керештем. Әнекәем! Бер сәгать тә үтмәде, укроп урынына кокос пальмалары калкып чыкты. Әйтерсең лә пальма урманы!

Пальмаларыма сокланып карап тора идем, Барс исемле мәчем килеп әлеге порошокны ялап алды. Мин шаккатудан мияулап куйдым — каршымда мәче түгел, юлбарыс ырылдап утыра иде — "Вискас" сорый, сөзә, ышкына. Ышкына гынамы соң, бульдозер кебек сөрә.

Зоопарктан белгечләр чакыртырга туры килде. Аларның андагы юлбарысларының кәнкәйгән чагы икән — минем Барсны алып киттеләр, шуңа алмашка дип...

Мин мәче белән маташкан арада эштән хатын кайтып керде дә ашка тоз урынына шул порошокны тондырган. Ике кашык ашны йотуы булды, башы түшәмгә тиде һәм миңа боера башлады:

— Нигә чиләктәге чүпне чыгарып түкмисең, ипи алып кайтмагансың, көне буе диванда әвәләнәсең? — дип, калын тавыш белән өркетә.

Колагына, гадәттәгечә, берне тамызырга теләгән идем дә, туктале, мәйтәм, порошоктан соң ул мине бер бармагы белән кандаланы сыткан кебек сытарга мөмкин бит дип уйлап эндәшми калдым.

Чыктым да балконга укроп чытырманлыгы арасына яшерендем. Алга таба нишләргә — белмим... Балконнан баш белән түбәнгә сикерергә микән әллә дип уйлап утырам.

Шулчак, шалт — башка бер уй килде: ә бәлки минем үземә әлеге порошокны кабып карарга дыр?

Һәм шулай эшләдем дә — баш – түшәмгә, иңем стенага бәрелде.

Көчкә балконнан чыгып, хатынга:

— Син ниндидер чүп чиләге турында сүз кузгаткан идең түгелме?

Аның мине күрүе булды — шым булды:

— Юк, юк, бернинди дә андый сүз булмады, җан кисәккәем? Шаярдым гына мин...

Шулай яшәп киттек — мин заводтан киттем — хезмәт хакына да тиеннәр генә түлиләр. Хәзер бер бизнесменның җан сакчысы булып эшлим — берүзем.

Хатын да үзенең конторасыннан китте — хәзер товар станциясендә вагоннар бушата — өч тонналы бер алымда. Үзенә үзе бригадир, дөресрәге, грузчиклар бригадасы...

Яшәү әйбәт! Тик менә мине гел бер уй интектерә — ничек кенә әлеге дә баягы порошок биргән ирне күрергә, малай бигрәк бәләкәй — ташбака, кенәри кошларга да каптырып алсаң шәп булыр иде ул даруны. Гел аяк астында буталалар, күреп тә булмый үзләрен... Бакча һәм андагы йорт турында әйтмим дә инде, буада ялтыравыклы карплар да бар бит...

Хөрмәтле укучым! Сизәсезме, гәүдәләребез зурайса да, фикерләвебездә әлеге порошокның зыяны сизелә. Шулай да минем миемдәге аек калган бер кузәнәгем болай ди: "Ашамлыкларга таракан үрчетә, укроп үстерә торган порошок сибәләр, күрәсең. Ризык кибетләрдә күптин-күп, ә хезмәт хакыбыз печтиктән дә печтик. Бүртәбез, җәмәгать, озакламый шартларбыз, мөгаен!..



"ЧАЯН" ШИФАХАНӘСЕ

БЕРНИНДИ ИСЕМЛЕКСЕЗ

Казанның шәхси медицина клиникалары пациентларының исемлекләрен төзүне планлаштыралар. Гади исемлекләр түгел, ә «кара» исемлекләр. Анда өметсез авыруларны түгел, ә күрсәтелгән хезмәт белән риза булмаган һәм биргән акчаларын кире таләп итүче «шикаятьче»ләрне кертергә җыеналар. Түләүле хезмәт күрсәтүче табиблар фикеренчә, андый «көйсез» пациентларның саны чиктән ашып арткан — чын мәгънәсендә шикаятьләр эпидемиясе башланган. Хәзергә табиблар мәсьәләне үзара хәл итүне хәерлерәк күрә. Ләкин проблема шеш кебек үсә бара, һәм аны тиз генә «операция»сез хәл итеп булмаячак.

«Кара» исемлекне төзегәндә бик күп уңайсыз сораулар туа. Төп сорау мондый: сәламәтлек сакчылары дәвалауның сыйфатлымы, сыйфатсызмы булганын ничек билгеләячәкләр һәм алар каршында чираттагы авыру шикаятьче утырмыймы? Өстәвенә, Гиппократ антын әлегә беркем дә гамәлдән чыгармаган – мөрәҗәгать иткән һәрбер кешенең медицина ярдәме алырга хакы бар. Һәм бернинди исемлексез...

Люция ГЫЙМРАНОВА



Михаил ЛАРИЧЕВ





Владимир ИЖБОЛДИН

Максим СМАГИН



Василий АЛЕКСАНДРОВ



СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

Шәхси клиникаларда иң дөрес диагноз пациентның матди хәленә куела.

Олыгайган саен, кешенең дуслары арасында табиблар арта бара.

Минздрав кисәтә: «Хәзерге вакытта бөтен нәрсә дә сәламәтлек өчен зыянлы!»

Әгәр табибка вакытында түләп барсаң, авыруыңның хроник форма алуы мөмкин.

“Бөтен авырудан шифа”лар күпме авыруны харап итте!

Хаталарда өйрәнәләр, хаталардан соң – дәваланалар.

Район поликлиника табибына барып җиткәнче, исән булу кирәк әле.

Никифор **ТУКМАЧЁВ**

ҖЫЕЛЫШ

Өй җиһазлары җыелып,
Кирәккәме, гадәтме?
Персональ эшен карыйлар
Кыңгыраулы сәгатьнең.

Сүз башлады Суыткыч:
– Эшләр тора коточкыч:
Сәгать эше былтырдан
Ничек каралмый торган.

Бу бик мөһим чара, ди,
Уйлап кына кара, ди.
Зурлар белән киңәшми,
Аралашмый, сөйләшми,
Һөнәр камилләштерми,
Чит телләр үзләштерми,
Бар белгәне тек, тә тек,
Киләчәктә юк өмет.

Сәгать сүз башламакчы,
Аңлатып акланмакчы.
Бүлде тузан суыткыч:
– Тыңлап тор, малакасус,
Бу бик тә начар гадәт;

Зурлар сүзен бүлдерү –
Үзлегең белән йөрү.

Тәнкыйть бүген урынлы,
Күтәрдең син угыңны.
Чыдарлык түгел холкың,
Әйтеп тормыйм минутын,
Секундларны санныйсың.
Айлар, еллар мөһимрәк –
Аны хисапламыйсың.

Сәгать сүз башламакчы,
Аңлатып акланмакчы.
Бүлде кер машинасы:
Планнарын тикшердем.
Башлыктан расланмаган.
– Планны арттырып үтәү
Эшләре башланмаган.

Тәнкыйть сүзе яудырдылар
Тәнкыйтьчеләр арганчы.
Җәмәгать, мин гаепле, дип,
Сәгать чалтыраганчы.




Василий **АЛЕКСАНДРОВ**





Ринат **АБЗАЛОВ**



Виктор **ФЁДОРОВ**

ГАБДЕЛБАРЫЙ ТӨПТӘН КАРЫЙ...

• • •

Ел башында иткә бәяләр күтәрелде. Бәхеткә каршы, колбаса җитештерүчеләр зыян күрмәде...

• • •

Аптека хезмәткәрләре мине маскалар киеп каршы алдылар. Бәя күрсәткечләргә күз салгач, моның талау икәнен аңлап алдым.

• • •

– Бутерброд ашарга тәки өйрәнә алмадың инде. Аны уылган дуңгыз тиресе, эмульсия, соя, крахмалын аска каратып ашарга кирәк.

• • •

– Шаярып, кешелек үзенең үткәннәре, элеккесе белән хушлаша, диләр бит. Менә мин дә, хуҗамнан көлеп, элекке эш урыным белән хушлаштым.

• • •

– Кешеләргә ярдәм итүдән беркайчан да баш тартканым юк. Кичә вокзал янында булдыра алган кадәр бүлешүемне үтенделәр. Һәм мин бүлештем – тормыш турындагы фикерләрем белән.

• • •

Хәзер сигарет капларына «Минздрав 101 нче тапкыр кисәтә!» дип яза башлаганнар.

• • •

– Төнлә фатирыма бәреп керделәр...
– Кемнәр? Коллекторлармы?!
– Юк, Ходайның рәхмәте, бары тик талаучылар.


• • •

Forbes исемлегендә соңгы булган бай да хатыны өчен булдыксыз.

Габделбарый ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВ







Вячеслав ШИЛОВ



Фәридә ХАҖИ

ОНЫТ!

Онытсаң оныт син мине —
Җәфалама, алдама!
Гомерем барыбер бергә
Әрәм үтәр алда да.

Күктән йолдыз бирәм диден,
Ләкин буең җитмәде.
Юлга гөлләр сибәм диден,
Вәгъдәләрең үтмәде.

Туйдым болытлы көннәрдән,
Кояш күрәсем килә.
Биздем салкын карашыңнан —
Иркәләнәсем килә.

Җилләр канатына кунып,
Хыялда очып йөрим.
Яшен яшьнәтер чагымда
Онытуыңны телим.

Алмаз ХӘМЗИН

МИН ШУНДЫЙ

Мин котыртам кеше күңелен
һәм язам дөресен чеметеп...
Мактаган да булып кыланам,
Кабартып, арттырып, чөертеп.

Күпләрнең, әй, килә ачуы –
Мин әйтәм хаклыкны яктыртып.
Денгә бик кертмәкче булалар,
Кайнатып, "акылга утыртып".

Наданнары аңсыз типкәли,
Аңлаганнар белеп тукмыйлар.
һич кермәс Хәмзә ипкә, диеп,
Чәйниләр, буалар, туныйлар!..

Андрей КЛИМОВ



Ринат МӘННАН

ФАРАЗ


Алда күп балалар туар...
Быел кояш "тилерде" —
Хатын-кызны, ир-атларны
Чишендереп бетерде.

Александр ЭЗЕКОВ

ҖӨМЛӘ

- Үзеңне беркайчан да башкалардан өстен куйма — яшен һәрвакыт иң биек агачка суга.
- Кунакның вакыты, хуҗаныкына караганда, күбрәк.
- Гаилә бәхетенең җәрәхәтләре бөтен гомергә кала...
- Сәламәтлекне сатып алып булмый... Аптекадагы бәяләр бирми.
- Алиментлар — гаилә тормышындагы җиңелү өчен контрибуция.

Валентин ДУБИНИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Олег ГОНОЗОВ

Яшәргә өйрәнү

Эшкә киткән чакта Бәширә иренең газ плитәсе янында утырганын күреп калды. Кайтуына ире нәкъ шул кыяфәттә, янган горелканың зәңгәр ялкынына сокланып утыра иде.

– Бәгърем, синең... бөтенесе дә тәртиптәме? – дип сорады ул. – Нигә аның дүртесен дә ялгадың?

– Аңларга телим: газ ике горелка, әллә дүрт горелка эшләгәндә күбрәк китә микән...

– Аңладыңмы соң?

– Юк әле...

Ике ай элек ул шулай ук, селкенмичә, ике көн буе ванна бүлмәсендә җеп буенча төшкән су тамчыларын күзәтеп утырган иде. Шул вакыттан бирле өйдә кранны бар көченә ачудан туктадылар, һәм ваннаны тәүлек буе кран тишегенә кертелгән җеп буенча тутыра башладылар. Ә юынган суны унитазны юып төшерү өчен файдалана башладылар. Нәтиҗәдә, су счётчиклары бөтенләй туктап калды!

Электр счётчигының әйләнүен әкренәйтергә Вәдүткә өч көн җитте. Дүртенче көнне электр счётчигының "суыткыч-кер юу машинасы" комбинациясендә "телевизор-микроволновка" һәм "тузан суырткыч-үтүк" комбинациясенә караганда, әкренрәк әйләнүе ачыкланды. Ике атна эчендә Вәдүт бөтен мөмкин вариантларны исәпләп чыгарды һәм таблица төзеп, хатыны белән кызына аны ятларга кушты.

Газ плитәсе каршында уйланып утырган ирен күрүгә Шәрапова кич белән тагын газ экономияләү буенча яңа таблицалар өйрәнергә туры киләчәк икән, дип, шөлләп куйды. Интернетка оптималь рәвештә чыгуның графигы инде күптәннән иң арзан тарифлы кәрәзле операторларның исемлеге янында зал стенасында эленеп тора иде.

Кырыс тормыш Вәдүтне бөтен мөмкин булган урында экономияләргә мәҗбүр итә иде. Йортта баскычтан менгән өчен түләү ала башлаячаклар дигән хәбәр чыккач, ул гаилә киңәшмәсе үткәрде. Анда ничек итеп фатирга балкон аша керә башлау турында сүз барды...

Зинаида ЗАХАРОВА

МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ

Яңа ел бәйрәме үтүгә авыл Советы рәисенә, шәһәрнең мәдәният бүлегеннән, телефонограмма килде. Секретарь кыз телефонограмманың сүзен сүзгә язып алды. Һәм рәис ишектән керүгә кулына язуны тоттырды. Быелгы ел “Мәдәният елы” дип игълан ителде, диелгән иде телефонограммада.

— Беләбез, беләбез, — дип сөйләнде рәис, укуын дәвам итеп. Беренче бурычыбыз — тел чисталыгы өчен көрәш башлау, диелгән иде телефонограммада. — Тагын мөгез чыгарырлар инде, — дип куйды рәис, язуны өстәлгә ыргытып. — Тагын юк белән заниматса итеп яталар. Безне эшсез утырталар, дип уйлыйлар, күрәсең. Әллә хулиганнар, эчкечеләр белән көрәшергә, әллә пенсионерларны кайгыртырга, әллә юлларны яңартырга, әллә тел чисталыгы өчен көрәшергә, белгән юк, панимаеш. Канишно телебез пычранды, анысы хак. Шул искелек калдыкларына каршы ничек көрәшергә генә белгән юк. Көрәшмәсәк тә районадагыларга эш күрсәтергә кирәк, — дип мыек астыннан серле генә елмаеп куйды рәис. Фантазияне эшкә җигәргә кирәк! Уйлана торгач, авыл халкына зур җыелыш уздырырга, диган фикергә килде. Агарту эшләрен башлап җибәрергә бик вакыт. Район вәкилләрен дә чакырырга онытмаска кирәк. Халыкка туган телебезне саклау, тел чисталыгының әһәмиятен аңлатырга вакыт җиткәндер. Ул тиз арада клуб мөдирен чакыртып алды.

— Җомга көнне кичке алтыга җыелыш җыябыз, — диде ул эшлекле кыяфәт белән. — Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә карала: тел чисталыгы өчен көрәш. Доклад белән үзем чыгармын. Минем докладны хуплап сөйләргә өч-дүрт кешене әзерләп куярсыз. Көн кадагына сугарлык булсыннар. Соңыннан авыл эшчәннәре концерты. Татар биюләре, татар җырлары, шигырьләр дә чиста – саф татар телендә булсын.

— Авылыбызда урыслар да яши ич, — дип каршы төште клуб мөдире Гөлниса.

— Аларга татарча өйрәнергә күптән вакыт, — дип, кызның сүзен бүлде рәис. — Татарстанда яшибез, панимаеш!

Менә көткән җомга килеп җитте.

Бәйрәмчә киенгән авылдашлары белән клуб эче шыгырдап тулгач, рәиснең күңелләре күтәрелеп китте.

— Ярата инде безнең халык бәйрәмнәрне. Бушлай концерт дигәндә, кырык эшләрен ташлап булса да килә, — диде клуб мөдире.

Район вәкилләре дә озак көттермәде. Аларны рәис белән мөдир урамга чыгып каршы алдылар.

— Тел чисталыгы өчен көрәш бик кискен булырга охшый. Бер машина төялеп килгәннәр, ярый ла сый җитәрлек булса, — диде клуб мөдире.

— Яхшы, күрсеннәр, белсеннәр, башкаларга үрнәк итеп куярга да онытмасыннар, — диде рәис.

Ул җыелышны башлап җибәрү белән залда тынлык урнашты. Ләкин озакка түгел. Чөнки рәиснең докллады бик озын, халыкны ялыктыр-



Иван ХАНТЕМИРОВ, «Чаян» № 22, 1972



Вадим МАЛЯКИН, «Чаян» № 9, 1991

ды. Докладта яңалык юк. Татар теленең бөек Тукай теле икәнен кем генә белми соң инде? Докладчының бөтен фикере шул турыда чуалды. Доклад нотык укуга корылган иде. Ә нотыкны берәү дә өнәми. Ниһаять, доклад тәмам булып, пренияләр башланды.

Беренче чыгыш ясаучы, балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче яшь, чибәр Гөлгенә Вәлиевна. Ул зал буйлап горур атлап сәхнәгә үтте, менгәндә кыска итәген тарткалап-тарткалап алды. Урысча сүзләр кушып сөйләшүгә чик куярга кирәк, диюгә рәиснең эченә җылы йөгерде.

— Инглиз телен белмәсәләр дә, сәлам диясе урында, “Һелло”, дигән булалар. Хәлләр ничек, дигән сорауга: “О-КЕЙ”, дип җавап кайтаралар. Нигә инглизләр һәм урыслар татар сүзләре кыстырмыйлар, ә без вата-җимерә урысча сөйләшкән булабыз? Балаларга үрнәк күрсәтеп, саф татарча сөйләшергә кирәк! — диде ул. Тик үзенең ике сүзнең берендә рус сүзләре кыстыруын гына сизмәде.

— Кайчан да кайчан инглизләр һәм урыслар татарча сөйләшә башлыйлар, без дә авыз йомып тормабыз! “О-кей”ны гына әйтә белербез, — дип тәмамлады ул сүзен.

Икенче итеп сүз колхозның баш агрономына бирелде.

— Басуларны басып алган чүп үләннәре белән дә көрәшеп арыган инде мин, — диде ул.

— Хәзер тел чисталыгы өчен чүп сүзләр белән дә көрәшергә кирәк икән, панимаеш. Минем өчен бу эш авыррак булыр кебек тоела ну, көрәшербез, — дип елмайды ул.

Шулчак эчкән өчен эшеннән куылган Гали торып басты. Аны күрүгә рәиснең йөрәге жу итеп китте. Баш бетте, дип уйлап куйды ул.

— Бу бит көлке, — диде Гали, кулларын селки-селки. — Нигә эчкечелек белән көрәшмисез? Менә мин – миңа гына каргагыз! Мин ник эчәм, дип уйлыйсыз? “Эш-сез-лек-тән”, — диде ул сузып. — Эш юк. Табып бирегез, эшкә урнаш-штырыгыз мине. Күпме яшьләр эшсез ята, панимаеш, нигә шул-ларга ярдәм итмисез? — диде ул тотлыгып.

— Үзләре гаепле, теләгән кешегә эше дә, ашы да бар, — дип кычкырды халык арасыннан берсе һәм рәисне коткарып калды, рәхмәт яугыры.

Йомгаклау сүзен рәис алды.


— Аллага шөкер, бик кирәкле, әһәмиятле карарлар кабул ителде. Тел чисталыгы өчен көрәш башланды. Бу сөйләшү күптән кирәк иде инде, — диде ул. – Патамушто татар телебез бик пычранды. Дейсвительнә, урыс сүзләре кушып сөйләшү пүчтәк ул, — диде. — Безне урыслаштырырга теләүчеләр бар. Кемнәр икәнен дә яхшы беләбез, не удасса! Не вазмёш, — диде дә, уң кулын, киноларда күргән Ленин бабайга охшатып, кискен генә күтәреп җибәрде. Халык, җыелышның ябык икәнен аңлап, рәисне көчле алкышларга күмде.

— Булды бит бу, — дип мыгырданып алды ул. Ихтыярсыз дигәндәй, йөзенә канәгатьлек билгесе чыкты.

Концерттан соң бик тәмләп чәй эчтеләр. Мөдирнең бәлешен ашаганда кунаклар “телсез” калды. Бигрәк тә бәлешнең төбе шәп иде. Авыл каймагыдай йомшак, авызга алуга эри дә китә.

— Болай сыйлагач, без гел килгәләп торырбыз, — диеште кунаклар, ниһаять, бәлеш ашалып беткәч. Рәхмәтләрне дә, мактау сүзләрен дә мулдан яудырдылар алар. Ашыга-ашыга рәиснең күчтәнәчләрен пакетларга тутырдылар. Ул килгән кунакларны озата чыкты.

— Молодцы, — диде район вәкиле, рәиснең кулын кысып. — Бу направление буенча да сез передовой урында.



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 10, 1966

– Хәзер без бу агрегатның җегәрлеген күтәрү мәсьәләсе өстендә эшлибез...



Акгөмбә һәм мушкетёрлар

(Урман халык әкияте)

Ниндидер бер патшалыкның гөмбәле дәүләтендә бәла килеп чыккан. Пычак, кәрзиннәре белән урманга гөмбәчеләр ияләшкән. Кирәксә-кирәкмәсә, каен, усак, нарат һәм ак гөмбәләрне төпләп йөриләр икән. Хәтта ал гөмбәләрне дә кызганмыйлар, ди. Кыскасы, барлык гөмбә кабиләләрен тамырыннан корталар.

Бу турыдагы хәбәр Акгөмбә патшага да барып җиткән. Ул барлык хезмәтчеләрен киңәшмәгә җыйган: ничек итеп үзләренең патшалыгын әлеге явызлардан коткарырга. Һәм болар, урман биләмәләрен саклау максатында, күрше урманнан Чебенгөмбәсе мушкетерларын ярдәмгә чакырырга карар кылалар. “Чебеннәргә” бер генә гөмбәче дә пычак күтәрергә батырчылык итмәс, чөнки алардан бөтенесе дә курка, хәтта чебеннәр дә якын килмиләр икән. Шулай булгач, менә шулар урманны сакласыннар!

Килешкән — беткән! Шулай эшлиләр дә. Чакыралар да “таплыбашларны”, аланнарга сакка куялар. Ләкин бу чара уңыш китерми. Гөмбәчеләр “чебеннәрне” читләп узалар да, рәхимсез рәвештә Акгөмбәнең туганнарын кыра башлыйлар.

Акгөмбә патша яңадан күршеләрен ярдәмгә чакырып мөрәҗәгать итә: зинһар өчен, “чебеннәр” гаскәре җибәрегез, дип. “Чебеннәр” шатланып баралар: һаман-һаман агылалар... Менә нинди нәрсә килеп чыга: чебенгөмбәләре бу патшалыкта артканнан-арта гына бара, ә мондагылары кими генә... Хәл шундыйга килеп терәлә, хәтта таплыбашлы генераллар Акгөмбә патша сараенда да чалына башлый. Һәм алар, фетнә күтәреп, тәхеткә үзләре менеп кунаклыйлар. Элеккеге патшаны һәм гөмбә советын кәрзингә томыралар, ә үзләре шушы патшалыкта хуҗа булалар.


Менә шушы урында әкият тә тәмам. Ә моның гыйбрәтендә нәрсә ятканын үзегез уйлагыз — акыллы булсагыз аңларсыз.



Валерий ТАРАСЕНКО




Эльвира ДЫШАЕВА



Илдус АЗИМОВ







Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

— Сезнең эштә “Классташлар” биктәме?

— Белмим.

— Бу җавабың өчен синең хезмәт хакыңны, һичшиксез, күтәрергә кирәк!

• • •

— Доктор, укол буламы?

— Ә тылсымлы сүз?

— Горздравка шикаять.

— Сез тылсым белән бөгештерәсез…

• • •

Хатыны иренә зарлана:

— Нәрсә без синең белән гел өйдә утырабыз, беркая да бармыйбыз. Әнә, күрше үзенең хатынын театрларга, музейларга алып бара…

— Бернинди дә тоткарлык юк, кадерлем. Кая телисең — рәхим ит! Фигуралы шууга барасыңмы?

— Әлбәттә! Кемнәр чыгыш ясый?

— “Ак Барс” һәм “Салават”.

• • •

— Син әти-әнием белән еш күрешәсеңме?

— Юк, сирәк…

— Нишләп алай?

— Без төрле социаль челтәрдә…

• • •

Озынборыннар хатын-кызларга караганда күпкә кешелеклерәк: әгәр дә инде ул синең каныңны эчә икән, ичмасам, соңыннан безелдәвеннән туктый.

• • •

Соңгы көннәрдә артык кызу булу сәбәпле, түзә алмадым — өйгә кондиционер куйдырдым. Дөрес эшләгәнмен! Икенче көнне үк яңгырлар ява башлады һәм салкынча булып китте.

• • •

Урманда бәйрәм. Барлык җәнлекләр исерек, җырлыйлар, биилә. Янәшәдән генә шактый нык салган, бәхетле чиктән ашкан аю пышылдап шуыша:

— Ниһаять, Маша кияүгә чыкты!

• • •

Шәһәр хастаханәсендәге палата.

— Мин хәзерге медицинаны нигәдер аңлап бетермим…

— Нәрсәсе аңлашылмый соң аның сиңа?

— Аз бирсәң — дәваламыйча гына кайтарып җибәрәләр, күп бирсәң — дәваламыйлар да, кайтармыйлар да!



Виталий ПОДВИЦКИЙ



МАТАЙЛАР һәм МАЛАЙЛАР

Мәетләрне җирләү бюросыннан мотоцикллар сату агентлыгына шалтыраталар:

– Сез бүген ничә мотоцикл саттыгыз?

– Бишне.

– Ә-ә, димәк бер җүләре һаман йөри икән әле...

•••

– Син мотоциклыңнан ризамы?

– Бөтенләй үк түгел. Йә мин, йә ул гел ремонтта булабыз...

•••

Янәшәдән узып киткән мотоциклчыларга карап утыручы машина йөртүчеләрнең күзләрендәге нәфрәт, «бөке» озынайган саен, көчәя бара.

•••

– Күршекәем, карале, мин бая мотоциклга атланган егетнең кызыңны утыртып урман ягына киткәнен күреп калдым... Ул-бу булмагае дип борчылмыйсыңмы?

– Пычагым булсынмыни аларга? Алар икесе дә шлем кигән ич!

•••

Урам хәрәкәте кагыйдәләре буенча имтихан бара.

– Сез урам чатында торасыз, ди. Уңда йөк машинасы, сулда автобус. Кайсысы беренче булып узарга тиеш?

– Мотоцикл.

– Нишләп мотоцикл??!! Каян килгән анда мотоциклчы??!!

– Шайтаным белсен аларны, каян килеп чыгалардыр...

Тимер атлар ярсуы

Безнең юлларда ни генә күрмәссең. Менә күптән түгел Чаллыда кешеләр искиткеч (бәлки, коточкыч?) манзара күзәткәннәр. Берәү, Тынычлык проспектында җәяүлеләрнең һәм автомобиль йөртүчеләрнең котын алып, мотоциклында... утыргычка баскан килеш җилдереп узган. Бу хәлне күргән кешеләр, әлбәттә, алган тәэсирләре турында порлициягә хәбәр иткәннәр. Тик “акробат”тан җилләр искән — мотоциклның номерлары булмаган!

Ике көпчәкле ат хуҗалары үзләренең тотышлары белән күпләрнең теңкәсенә тия. Алар катнашында булган юл вакыйгалары саны моңа дәлил булып тора: бары тик ярты ел эчендә Казанда тимер ат җайдаклары катнашында егермедән артык авария булган.

Ваемсыз байкерлар автомобиль йөртүчеләрне һәм җәяүлеләрне генә түгел, шәһәр читендәге микрорайоннарда яшәүчеләрне дә борчый. Күп кенә “төнге ковбойлар” караңгы урамнар буйлап мотоциклларының тавыш йоту җайланмаларын алып ташлап кудырталар. Алар үзләренең һәм башкаларның куркынычсызлыгы турында соңгы чиратта уйлыйлар. Моның бик тә хәвефле нәрсә булуын дәлилләүче берничә мисал китерәбез. Бәлки, алар кайбер кайнар башларны бераз суытыр.

Казанның үзәгендә “KIA” һәм егет белән кыз утырган “Ямаха” юл бүлешә алмыйлар. Каты бәрелүдән гашыйклар автомобиль өстеннән очып чыгып, асфальт өстенә түшеп кунаклыйлар. Мондый мәтәлчектән соң алынган имгәнүләргә карамастан, тизлек сөюче пар исән-имин кала. Ә менә “Ямаха”ның хәле мөшкелрәк була — аны турыдан-туры металлоломга гына җибәрәсе кала.

Ләкин язмыш бөтен кешегә дә бер үк төрле рәхимле була алмый шул. 13 июльдә икенче бер яшь пар төнге Казан буйлап сәгатенә 140 километр тизлек белән җилдергәндә Глушко урамы һәм Җиңү проспекты чатында “Приора”га барып чәпелә. Моның нәтиҗәсе бик күңелсез була: егет белән кызга инде бернинди ярдәм кирәкми...

Даими рәвештә тәртип бозуларына карамастан, байкерлар “хокукларын” бик гайрәтләнеп яклыйлар. Күптән түгел полицейскийлар рейд вакытында руле төзексез булу сәбәпле, бер “ковбой”ның тимер атын алырга маташканнар. Нәрсә башланган монда! Ярдәмгә килеп җиткән дуслар гаишниклар белән хәтта бәргәләшеп тә алганнар...

Бу җәнҗал ЮХИДИ җитәкчеләре белән мотоцикл сөючеләрнең очрашуына сәбәп булган. Кайнар канлы егетләр беренче эш итеп дәгъва белдергәннәр: имеш, полиция аларны сәбәпсез “кыса”, болай дәвам итсә, алар протест йөзеннән номерсыз йөри башлаячаклар.

Гаишниклар, үз чиратларында, аларны махсус рәвештә беркем дә “ауламый”, ә законның бөтен юлда йөрүчеләр өчен дә бер булуын аңлатканнар. Законнан бит хәтта иң “крутой” “харлей”да да качып китеп булмый. Ә китәргә тырышканнарны барыбер йә кырыс инспектор, йә реанимация бүлеге түшәге туктата...

Азат ЮЛДАШЕВ



Михаил ЛАРИЧЕВ




Илдус АЗИМОВ



Дмитрий КОНОНОВ


Илле мең!
КАССА
Өч айлык хезмәт хакы белән хатынны шатландырыйм әле!
ЗАВОД
Малыңмы, жаныңмы?
ХРЯСЬ!







Илдар НӘФИЕВ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Эшли белгән кеше эшли, эшли белмәгәне башкаларны өйрәтә; ә тегесен дә бусын да белмәгәне остазларын өйрәтә.

Укучыларның хәтеренә укытучыларның хаталары тирәнрәк сеңеп кала.

Белем алу — яхшы һәм бай тормышка туры юл. Ләкин мәктәп укытучылары моңа дәлил була алмый.

Фән өйрәнгәндә мисаллар кагыйдәләргә караганда файдалырак.

Кирәкмәгән нәрсәләрне үзләштерә алмаган укучылар гына галим була ала.

Яхшы укытучы үзе белмәгән нәрсәгә дә өйрәтә ала.

Мәктәп безне булмаган дөньяда яшәргә өйрәтә.

Хәзерге аттестат аның иясенең ничә еллар буе мәктәптә укуга түзгәнлеген генә раслый ала.

Мәктәп — урам ташларын шомарта һәм мәрҗәннәрне боза торган урын.

Бернәрсә дә укымаган кеше бары тик газеталар гына укый торган кешегә карата белемлерәк.

(Мөгаллимнәр киңәшмәсендә язып алынды)

Сергей АНДРИАНОВ





ТЕЛЕФОН ТЕРРОРЧЫЛАРЫ

Кадерле редакция! Көтмәгәндә-уйламаганда телефон террорына юлыктым бит әле. Юк, балконга яисә йортка шартлаткыч куйдым, дигән янаулар белән шалтыратмадылар. “Минем” террорчылар башкача эш йөртә...

Күптән түгел АВИТОга белдерү бирдем, шунда телефонны да күрсәтергә туры килде. Менә шуннан башланды инде тамаша. Шундук шәхси клиникалардан бертуктаусыз шалтыратулар ява башлады. Баксаң, минем телефон зур җиңүләргә ирешеп, косметология процедуралары откан икән. Яисә сер булып калырга теләгән дусларымның берсе минем исемгә сертификат алган, имеш... Шалтыраткан адәмнәр “Саулык” газетасы хезмәткәрләре дип таныштыра, йә “Контроль сатып алу” программасы ияләренә тиз арада әлеге клиника турында минем фикерем кирәклегенә ышандырырга маташа.

Шалтыратуларына аптырап калсам да, башта җавапларымны бик әдәпле бирдем. Аннан, түземлегем бетеп, кырысрак сөйләшә башладым. Алай да барып җитмәгәч, “ачык текст белән” озата башладым. Телефонның теге башыннан: “Клиникабызга килмичә, без шалтыратудан туктамыйбыз!” — дигән җавап кына ишеттем. Блокировкага да куеп карадым, ләкин шалтыратучылар яңаданяңа номерларын кулланалар. Әллә ФСБ хезмәткәрләренә шалтыратып, әлеге телефон террористлары янавына шикаять язаргамы икән дип уйланып утырам әле менә. Мине һәм башка телефон террорчылары корбаннарын, бәлкем, азат итәрләр иде әлеге янаулардан?

И. РӘХИМОВА

КАЗАН

ЮНЬЛӘП ЭШЛӘМӘДЕЛӘР...

Кадерле Чаян! "Могҗизалы тамашага исәң-акылың китәрлек!" дип язган иде бер шагыйребез. Һәм без, Тынычлык бистәсе халкы, тулаем аның сүзләре белән килешәбез. Безнең краннан аккан төрле төстәге су – могҗиза түгелме? Бер караганда – күгәргән әфлисун төсендә ага, икенче юлы инде сөтле кофе төсләрен алган була... Хет "Сәер күренеш" программасыннан күрсәт...

Берничә ай элек Столичная урамы 6 нчы йорт торбаларын алыштырырга булдылар. Тиздән төсле могҗиза юкка чыгачак, үз төсендәге су агачак дип безне дә ышандырдылар. Күп тә үтмәде, су үткәргеч торбаларны төзекләндереп тапшырдылар да. Әйе, краннан үз төсендәге су ага башлады. Ләкин ниндидер кара кисәкчәләр белән "баетылган". Киләчәктә шланг һәм краннарның чүпләнеп тузуын көт тә тор...

Шагыйрь язганча: могҗизалы тамашага исәң-акылың китәрлек... Бер сәер могҗизадан котылып, икенчесенә тап булдык.

Г. ХӘЛИМОВ

ЯШЕЛ ҮЗӘН

КӘКРЕГӘ – ЧАЛЫШ

Чаян дус! Белгәнебезчә, яңа автобус маршруты ачып җибәрер алдыннан белгечләр пассажирлар агымын өйрәнә. Безнең торак пункт та белгечләр игътибарыннан мәхрүм калмагандыр. Ләкин алар фикере безнең файдага булып чыкмады. Ун ел элек безне шәһәр састава кертүләренә карамастан, юл тамашасы белән ничек азапланган булсак, әле дә шулай – берни үзгәрмәде. Әлбәттә, 84 нче маршрут автобусы җибәрделәр. Ләкин килү-китү вакыты халык теләгәнчә түгел. Иртәнге сәгать 6 дан кичке 7 гә кадәр генә йөри. Расписание буенча маршрут арасы 1 сәгатьтән артып китә. Ә көндәлек тормышта ничек килеп чыга инде? Халыкка үзенең җаена такси тотып йөрергә кала.

Әгәр дә мәгәр безнең бастырган хаттан соң пассажирлар агымын тикшерә башлау да берни бирмәячәк. Чөнки расписаниесе җайлы булмаганлыктан, халык аз йөри.

КАЗАН

ЧЕБАКСА бистәсе халкы

ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ КАЙГЫСЫ

Чаян дус! Син еш кына йортларына болганчык, тәмсез, сасы – кыскасы, начар сыйфатлы су килгән укучыларның хатларын бастырасың... "Их, безгә иде сезнең кайгы!" – дип уфтана аларны укыгач, Алексеевский районының Урта Тигәнәле авылында яшәүчеләр. Аларның авылында еш кына су бөтенләй булмый! Әгәр дә краннардан бераз челтери икән, анысы да авылның өске өлешендә генә. Ә "түбәноч"ка су барып җитми – әллә су басымы җитми, әллә башка бер сәбәп белән...

Авыл кешеләре су мәсьәләсе буенча күп тапкырлар җирле хакимияткә мөрәҗәгать итеп карадылар инде, ә җавап һаман бер: акча юк, түзегез инде, нык торыгыз! Әйтергә кирәк, авыл юлын ремонтларга да акча юк (кайчандыр аны авылдашлар бергәләшеп җыйганнар иде). Ул хәтта таш белән дә капланмаган. Кызыл балчык өйделәр дә, шул килеш калдырдылар. Яңгыр яуганнан соң карыйсың да, монда пычракка баткан иномаркаларның экстремаль узышларын күз алдына китерәсең. Һәм аларга карап: "Их, менә безнең кайгыны кемгә өяргә иде!" – дип уйлап куясың...

И. ИБӘТУЛЛИН

АЛЕКСЕЕВСКИЙ районы



Андрей КЛИМОВ



Игорь КИЙКО



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Хатын телевизордан юлбарыс белән кәҗәнең сокландыргыч дуслыгы турында тапшыру карый.

— Күңелләрне эретерлек хәл бит бу. Беләсеңме, җаным, әгәр дә син юлбарыс Амур яши торган вольерга килеп эләксәң, ул сиңа тимәс иде, һәм сез, минем уйлавымча, һичшиксез, дуслашыр идегез.

— Каян уйлап чыгардың әле син моны? — дип гаҗәпкә кала ире.

— Син ныгытып уйла әле... ныгытып уйла!..

• • •

Футбол уены вакытында “Рубин” җанатары “футболчы” сүзенә 198 мәгънәдәш сүз кулланган.

• • •

— Бабай, яшь чагыңда син күпме покемон тоттың?

— Без үскәндә бит покемоннар юк иде, булса шул яшел кешеләр һәм “белочка”лар гына булгандыр.

• • •

— Нишләп син өйдә гел шул бер трусиктан йөрисең?

— Чөнки икене кисәң бик эссе!

• • •

— Минем сөйгән ярым туйда кәләшнең күккә чөйгән чәчәк бәйләмен тотты. Хәзер аның белән ничек очрашачакбыз икән соң, ул бит кияүгә чыгачак?

• • •

— Син перфоратор белән эшләгәндә күршеләрең зарланмыймы?

— Юк, мин бит алар йоклаганда, төнлә эшлим.

• • •

Полицейский карап-тикшерүнең протоколын яза:


— Ир кеше, 40 яшь, башында каты әйбер белән суккан эзләр (таба). Хатыны сөйләвенә караганда, ул аңа ябыгу өчен таблеткалар сатып алырга теләмәгән, бу яшьтә инде аларның бер файдасы да юк, дигән. “Үзен үзе үтергән”, — дип язып куябыз.

• • •

Өй нигезе кырыена утырып, ике әби сөйләшә:

— Карале, ахирәт, минем онык кичә ниндидер “покямоннар” эләктергән.


— Кызлар артыннан күп чапсаң шулай була ул! Мин бер җирдә яхшы врачны беләм...



Михаил ЛАРИЧЕВ




Илдар НӘФИЕВ



Виктор ФЁДОРОВ

Фазыл ИСКӘНДӘР



Зур акыллы һәм шат күңелле даһи Фазыл Искәндәр вафат булды. Ул – кайчандыр бөек һәм бердәм булган илнең берничә укымышлы буыны тәрбияләнеп үскән китаплар иҗат иткән асыл язучы. Бөтен заманнар өчен язылган Чегем авылыннан зирәк Сандро агай турындагы эпосы аны бар дөньяга танытты. Бүгенге көннең әдәби каһарманы – яңа «Поттер» тирәсендәге шау-шу янында Искәндәрнең бөеклеге аеруча якты күренә. Нишлисең бит, заманасы нинди булса, китаплары да шундый...

Кеше ул – дәрәҗәсе буенча кәҗә белән Шекспир арасындагы сәер зат.

И тормыш, сабакларыңның катылыгы белән түгел, ә серле аңлаешсызлыгы белән дәһшәтлерәк син!

Озакка сузылган рәхмәт укуны тыңлаудан да авыр нәрсә юк.

Оят ул — хатын-кызны бизи торган иң затлы күлмәк.

Әгәр дә илдә китап урламый башлаганнар икән, димәк, бөтен башка нәрсәне урлыйлар.

Гражданлылык — ул тәмәке төпчегеңне чүп савытына кадәр илтергә иренмәү. Дәүләтчелек – бу юлны ялыктырмаслык итәргә тырышу.

Хатын-кызлар — товар киштәсе белгечләре.

Күбрәк эчкән саен, аның көнчелеге ыграк айный барды.

Алар берсенә дә кирәкмәгән һәм шуңа күрә күңелгә ятышлы әйберләр турында сөйләштеләр.

Менә шулай, берәр яхшылык эшләргә мөмкинлек туды исә без артык аек булабыз, ә сирәк кенә акыллы киңәш бирергә кирәк чакта лаякыл булып чыгабыз.

“Кар кешесен” эзләү — ул кешелекнең үзенең якынаеп килүче ахырын тоюдан килә. Кеше, үзенең кайчан абынганын аңлар өчен, борынгы бабасын күрергә тели.

Гүзәл хатынның ахмаклыгын күрмәгән кебек, ахмак ирнең матурлыгын күрмәскә мөмкин.



Валерий ТАРАСЕНКО



Күпсанлы юбилей-алкышлар арасында бер кечкенә дата югалып калган. Нәкъ алтмыш ел элек «Чаян»да Эрнест Дышаевның беренче карикатурасы дөнья күрде.

Аның турында нинди генә купшы сүзләр сөйләсәк тә, аз булыр кебек – тере классик, журналыбызның йөзе, «Чаян» тарихының аерым эпохасы… Иң танылган һәм барчабыз да бер караудан танып ала торган рәссам, темалар авторы, кабатланмас графика остасы Дышаев – тормышта бик тыйнак һәм чын мәгънәсендә интеллигентлы кеше. Бәлки, шуңа күрә аның бер генә дә (!) «фәлән өчен, төгән өчен» бирелә торган рәсми бүләге юктыр. Ләкин аның күпкә мөһимрәк нәрсәсе – ул да булса карикатура дөньясындагы даны һәм иҗаты белән яулап алынган халык рәссамы дигән исеме бар.

Эрнест ДЫШАЕВ





“Чаян”дагы беренче рәсеме (№ 20, 1956)




“Чаян” (№ 11, 1998)



– Хезмәткә яраклы булып болар гына калды!

“Чаян” (№ 4, 2003)





Эрнест ДЫШАЕВ рәсемнәре

АХЫР ЧИККӘ ҖИТКЕРДЕЛӘР

Бу көннәрдә генә, ресторанда, янәшәдәге өстәл кырыенда тузган фрак кигән бер картны күзәтеп утырдым. Ул, янына килгән официанттан бер рюмка аракы сорады. Официант, канәгатьсезлек билгесе чыгарып аптырап калды. Бабай аңа йорт-җире өчен салымнар түләгәннән соң бер тиен дә акчасы калмаганын аңлатты. Шуңа күрә бик аз күләмдә аракыга заказ бирергә мәҗбүр булуын әйтте. Бик авырлык белән очын очка ялгап яши икән. Мин телсез калдым. Тиз генә бер шешә “Столичный”га заказ биреп, картның алдына куйдым. Ул миңа кат-кат рәхмәтләр әйтеп, кабалана-кабалана рюмка арты рюмка аракыны авызына каплый башлады. Мин үкереп елый-елый өйгә кайттым. Нинди чиккә җиткергәннәр бит кешене!

Икенче көнне банкта Бронионни фирмасында тегелгән костюмлы ирне күрдем. Ул, бик күңелсез генә, кулында соңгы марка айфон әйләндергәләп, төрле операцияләр үткәрә торган зал почмагында тора иде. Ул эшкуар булып чыкты. Салымнар, штрафлар, өстәмә процентлар, суд карарлары һәм алиментлар түләгәннән соң, аның акчасы ашарына да калмаган икән. Өлкән эшмәкәр, банктан кредит юнәтеп, соңгы марка мерседес алмакчы икән. Ләкин кан эчкеч банклар аның теләген кире каккаННар. Аңа каравы да кызганыч иде. Мине бу хәл тетрәндерде. Мин шундук аңа үземне поручитель итеп тәкъдим иттем. Шатлыгыннан күзләренә яшь килгән эшмәкәр миңа бик озак рәхмәтләр укыды. Үзе ашыга-ашыга вак хәрефләр белән язылган ниндидер кәгазьләрен суза, мин кулымны куям, үзем елыйм. Нинди ахыр чиккә җиткергәннәр бит кешене!

Кичә урамда әллә нинди төксе бер адәм очрады да тартырга сорады. Милкенә салым түләгәч, акчасы калмаганын әйтте. Мин тетрәндем. Уйлап та тормый, аңа тәмәкемне, барлык акчамны, телефонымны, сәгатемне, паспортымны биреп калдырдым...

Ул миңа башын ия-ия бик озак рәхмәтләрен укыды. Ә мин өйгә таба борылдым, бу хәлгә чыдый алмый – еларга тотындым.

Кешеләрне нинди чиккә җиткергәннәр бит!

Марат КАЗИЕВ



СЕКСПЛУАТАЦИЯ КОРБАННАРЫ

Хыял — татлы нәрсә. Хәтта аның иң тыелганы да. Дөрес, татлы хыял еш кына ачы чынбарлыкка да әверелеп куя. Берзаман Казанда яшәүче Рузана Сабитова зур табыш китеручe... фәхешханә булдыру турында хыяллана башлый! Уйлары белән элек хөкемгә тартылган Эдуард Галиев белән уртаклаша. Тегесе, уйлап та тормыйча, танышлары О. Еврошин һәм А. Хаҗиәхмәтовны ярдәмгә тартып, хыялый ханымның планнарын тормышка ашыра башлый. Бу "бизнес"та алар "тере товар" табып китерергә тиеш булалар.

«Яшь кызлар өчен яхшы түләүле эш». Яшь туташ Эльвира М. нәкъ шушы белдерүгә каба. Вакытлыча яши торган фатирында Руза түтәй аны якты йөз белән каршы ала. Кызны баштанаяк карап алганнан соң, ул аның документларын сорап ала һәм кәнәфидә җәелеп утырган Әлмәт кызы Света, Түбән Камадан Лилия һәм Бөгелмәдән Лена янына чакыра. Җәелеп утырырга озак туры килми. Тиздән бүлмәгә дүрт исерек егет килеп керә. Турыдан-туры ясалган тәкъдимне куркып калган кызлар кире кага. Менә шунда, күп сөйләшеп тормыйча, аларга иң шакшы "эш" тәкъдим итәләр.

Кызлар, документларын кире кайтаруны сорап, үзләрен җибәрүне үтенәләр. Ләкин Сабитова үзен каты тота. Тоткыннарның берсе, мөмкинлек табып, качарга маташканда, ишек янында Руза түтәйнең "хезмәттәше" Галиевка юлыга. Тегесе кызның яңагына сугып җибәрә — һәм "яхшы түләүле эш" эзләп килгән туташ клиентларның барлык теләкләрен үтәргә мәҗбүр була.

Әйтергә кирәк, Рузана Сабитова тарафыннан тәкъдим ителгән специфик "хезмәт" ир затларының кайберләренә хуш килә — "ятак бизнесы" чәчәк ата. Дөрес, "сәер" фатирдан килгән шау-шу һәм аһылдауыңгырашу тавышлары тын микрорайонда яшәүчеләргә ошап бетми. Шуңа күрә "ханә", конспирация таләпләренә туры китереп, еш кына адресын үзгәртеп торырга мәҗбүр була. Ләкин "саклану чаралары" җитәрлек дәрәҗәдә үтәлми, күрәсең — Руза түтәйнең яшерен фирмасы ачыла. Чөнки, беренчедән, тән ләззәте өлкәсендә хезмәт итүче "кызларның" саны йөздән артып китә. Икенчедән, биш ел эчендә "хезмәттәшләр", кыюланып китеп, конспирациягә бик җиңел карый башлыйлар. Хәтта кызларның берсен башка "фирма"га сатуга барып җитәләр. Утыз мең сумга! Килешенүне тормышка ашырырга полиция хезмәткәрләре комачаулый...

Мондый мисаллар исемлеген, кызганычка каршы, дәвам итәргә булыр иде. Мәсәлән, күптән түгел А. Эбель һәм И. Нәбиуллин җитәкчелек иткән сутенёрлар төркеме хөкемгә тартылды. Алар өч ел дәвамында, зур акча вәгъдә итеп, кызларны интим-бизнеска тартып килгәннәр. Аннан соң, куркытып, аларны сатлык мәхәббәт яратучы ирләргә хезмәт күрсәтергә мәҗбүр иткәннәр. Киреләнгәннәре белән сүзне кыска тотканар: кыйнап, чылбырга утырта торган булганнар.

Югары суд Руза түтәй һәм аның компаниясенә төрле сроклар биреп, алар эшендә нокта куйды. Әмма Казанда бу охшаш "фирма"лар бүтән булмас дигәнне аңлата аламы? Беркатлы яшь кызларны "эшкә" чакыручы белдерүләргә караганда, бу табышлы кәсепне дәвам итәргә теләүчеләр йоклап ятмый. Һәм башкаларны да йоклатмый...

Айдар СУБАЕВ



Валентин ДРУЖИНИН



Александр ЛЕВИТИН







ЧуАр пресса

ГӨМБӘГӘ БАРГАННАР

Россиядән бер гаилә Швейцариядә ял иткән. Алар, яхшы кунакханәгә урнашканнан соң, якындагы урманга һава суларга киткәннәр. Урманда гөмбә бик күп булып чыккан, һәм ир белән хатын аны күп итеп җыйганнар. Кеше кул-аягы тимәгән гөмбәле җир аларга тынгы бирмәгән, һәм алар урманга тагын берничә мәртәбә барганнар. Кунакханәнең персоналы Россиядән килгән гаиләнең номерында бер ванна тозлаган гөмбә тапкач шаккаткан.

УТ БЕЛӘН УЕН

Олимпиянең факеллы эстафетасын 1936 елда Берлиндагы Олимпиаданы оештыручылар уйлап чыгарган һәм беренче мәртәбә уздырган. 1956 елны Мельбурндагы уеннар алдыннан җирле студентлар, фашистлар уйлап чыгарган бу эстафетага каршы, үзенә күрә протест акциясе уздырганнар. Алар гади өстәлнең аягын керосинга манчылган чүпрәк чорнап, шуны чын факел тоткан официаль йөгерүчедән алдарак Мельбурнның мэрына тоттырганнар.

«М» НАН «Ж» ГА

Бервакыт җәмәгать бәдрәфендә британияле Марк Эллис стенада Доннага шалтыратуларын сорап язылган телефон номерын таба. Кызык өчен, шул номер буенча шалтырата. Аннан соң алар очрашалар, бер-берсенә гашыйк булалар һәм озак еллар буе бәхетле яшиләр. Язмышны хәл иткеч бу язуны бәдрәф стенасына Доннаның элеккеге егете язып калдырган була. Ирексездән, начарлык эшләргә теләп, аны бәхетле иткән.


КАМЕРАДАН КАМЕРАГА

Кытайның юл полицейскийлары бер йөк машинасында видеокамерадан автомобиль номерларын яшерүнең гадәти булмаган ысулына тап булганнар. "Куркыныч" урынны узганда, икенче машина йөртүче, бамперга менеп, номерны үз гәүдәсе белән каплаган. Мондый эш өчен Кытай гаишниклары бу тапкыр шоферларны эзләп тапканнар һәм штраф салганнар.





Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр



Жан-Марк РЕЙЗЕР (Франция)




Отоо РЕЙЗИНГЕР (Хорватия)




Генри БЮТНЕР (Германия)



Мирослав БАРТАК (Чехия)



Ежи ГЛУШЕК (Польша)



Иржи САЛОМОН (Словакия)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

— Кадерлем, кем шалтыратты?

— Мин аңлап бетермәдем. Ниндидер ир. Һава торышын әйтә торган кешегә охшаган…

— Нигә шулай уйлыйсың?

— Соравы бик сәер тоелды миңа: “Ну нәрсә, кояш, офыкларың аязмы?” — ди.

• • •

Киләчәк буын галимнәре татуировкасыз кешеләр нинди булганнарын белсеннәр өчен, үземнең гәүдәмне васыять итеп калдырам.

• • •

— Кадерлем, үзеңнең туган көнеңә нәрсә телисең?

— Битемне чистарту өчен косметологка барырга телим.

— Димәк, әгәр миннән нәрсә бүләк иткәнемне сорасалар, синең чыраеңны матур итеп әтмәлләргә уйлаганымны әйтергә кирәк, әйеме?!

• • •

Мин яңгыр тамчылары шаулавыннан йокыга китәргә яратам… Тыныч кына су чайкалуы һәм агымы тирән йокымсырау өчен шулхәтле рәхәт… Ул чакта тәрәзә артында минут саен мотоцикллар пырылдавы да ишетелми. Гөрләвектә йөри алмыйлар.

• • •

Хатыны ирен ачулана:

— Күпме эчәргә була? Зиратка барып кара, нихәтле кеше шул аракыдан үлгән!

Икенче көнне ире тагын исерек килеш кайтып керә дә әйтә:

— Зиратта булдым, күрдем, “Хатыныннан”, “балаларыннан”, “коллективыннан”, ә менә аракыдан дигән берәү дә юк!

• • •

Җәмәгать транспортында һәрвакыт табигать сакчыларын очратам. Алар озон катламын саклау өчен дезодорантлар да кулланмыйлар, суны исраф итмәс өчен юынмыйлар да.

• • •

Эчмим дисәм, бөтенесе эчертергә маташа; диетага утырыйм дисәм, ашатырга тотыналар! Ә менә акча юк, дисәм — әллә әкрен әйтәм, әллә начар ишетәләр…

• • •

Ирем командировкада, үзем өйдә ялгызым гына дип язмыйм әле! Андый чакта, ягъни статуста язу килешмәс! Йә Окольный урамындагы 15 нче йортның 10 нчы фатирына (3 нче подъезд) теләсә нинди ирләр килә башлар. Ишекләр дә бикле түгел…

Евгений ОБУХОВ

Кешелеккә мәхәббәт

Төрле яктан төрлечә якыныңны яратырга кушсалар да, килеп чыкмый әле ул бездә, күңелне биетми, җанны җылытмый бөтен кешелек дөньясына мәхәббәт уяту, дөресрәге – уйнату.

Мин, мәсәлән, тырышып карадым. Ниндидер бер апа юлны аркылы-торкылы чыгып йөри, ә машина йөртүче көчкә туктап өлгерде. Әй акырырга тотынды шуңа апакай, әй акыра!.. Мин шунда аңа җайлап-майлап кына аңлатырга керештем:

– Сез нигә шулхәтле җикеренәсез әле? Чыгырыгыздан чыгып. Әллә ирегез юкмы? Булса болай булмас идегез, ул сезнең белән күптән... теге ни...

– Нәрсә, теге ни?! Әйтеп бетер!..

– Ни дип әйтим, нитмәүне әйтәм...

Шалт миңа сумкасы белән башка! Ә анда өч литрлы банка белән тозлы кыяр. Иренә үчен миннән ала!

Бер тапкыр, кояшка сокланып, урам буйлап барам. Каршыма тач Гамлет шикелле берәү килә – уйчан, арт шәрифләрен уйната – шаккатарсың. Мин аңа чын күңелемнән:

– Сез ниндидер гаҗәеп тегенди-мондый?.. Мин бит сезне яратам, ир зат!

Аның шатланганын күрсәгез!

– Чыннан яратасыңмы? Алайса, җуләркәем, әйдә безгә...

Көчкә ычкындым. Буталып, футбол җанатарлары төркеменә барып кергәнемне сизми калганмын. Аларга кычкырырга тотындым:

– Нишләп сез киоскны һәм афишалар тумбасын аударлыгыз? Футболны гына яратырга димәгән, тирә-юньдәге барлык әйберләрне яратырга кирәк! Менә мин, мәсәлән, бетенесен яратам!

– Бөтенесен?! Спартаклыларны дамы?! Ну, чеберчек!..

Хастаханәдә ятып чыкканнан соң, подъездда күршем очрады.

– Барыгызны, – димен, – яратам!

– Барыбызны?! Минем хатынны дамы?! Әле син шулаймы, кабахәт!..

Мин боларны ни өчен әйтәм: метрода үзе генә бер кыз бара. Йөзендә сагыш, телевизордан мәзәкләр карап утырган, күрәсең. Сүз башладым:


– Нәрсә булды сезгә? Нигә ямансу? Мин яратам бит сезне!

– Шулаймыни? Алайса, давай, өйлән!..

Мин, әлбәттә, аңа бөтен дөнья кешелеген яратам дип аңлатмакчы идем, ләкин ул миңа бөтен күкрәк "кавын"нары белән капланды, һәм... соң иде инде... Хәзер бергә яшибез...

...Язучы Горький бер мәртәбә бик дөрес итеп әйткән, кеше күктәге бәхетле кош кебек очар өчен туган, дип. Мин Горькийны яратам кәнишне, ләкин аның бу фикере белән килешеп бетмим. Чынлыкта кеше бәхет теләр өчен туган! Менә асыл нәрсәдә! Мин, мәсәлән, бик-бик кайнар һәм көчле рәвештә үземә бәхет телим. Ләкин бу ничектер килешеп бетми, куандырмый... Бәлки, ул мине берәү дә яратмаганнан килеп чыгадыр? Кешечә аңлавымча – шулайдыр?!.

Вячеслав ШИЛОВ



ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлаячак. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»ны катлаулыкларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.

Бу очракта язылу индекслары татарча журналга – П2438, ә русчасына П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Алар буенча Россия һәм Татарстан укучылары языла ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып балкып керсен!

Уйна да, уйла да!

ГАРМУНЧЫ ГАЛИ ...
ШӘҺӘР РАЙОН ҮЗӘГЕ
СОВЕТ КОСМОНАВТЫ
ТАРТ-ТЫРЫЛГАН ЯРМА
"... КАНАТЫ АТ БУЛА"
ШАГЫЙРЬ ... МИФТАХОВ
"СӘЯН ЖАНЫМ-(-1)ЕМ БЕЛӘН"
ТОРМЫШ БАШЛАНГЫЧЫ
КОМПОЗИТОР ШӘМСЕТДИНОВА
НОТА
"МИНЕМ АТЫМ УЙНАГАНДА КИН БОЛЫННАР БУЛА ..."
"... БАСМАЛАРЫ"
ИНГЛИЗ ПРИНЦЕССАСЫ (-2)
БУРАНЫҢ ДҮРТ БЕРКЕТЕЛГӘН БҮРӘНӘСЕ
"... ДӘН ҮЗӘ"
"ЧАЯН"НЫҢ ЖОР ТЕЛЛЕ АГАЕ
КИПР — ... ДИҢГЕЗ УТРАВЫ
СӨЕНЕЧ, КУАНЫЧ (-2)
ЯЗГЫ ...
"КҮҢЕЛЕМДӘ — САРЫ САГЫШ"
"ТАУДА" (САЛАВАТ) ӘСӘРНЕ ИЖАТ ИТҮЧЕ
(-1) КОМПЬЮТЕРНЫ СУЫТУ ЖАЙЛАНМАСЫ (ИНГЛИЗЧӘДӘН)
"НЕЧКӘ ..." КОНКУРСЫ
"ӨЧЕНЧЕ КӨН ӘРНИ УЛ ..."
ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН ...
"СИН ХАКЛЫ КЕЩЕ ИДЕҢ (ТАКТАШ)"
(-1) СТАТУЯ
"... БУЙЛАРЫ"
"АЕНА ТҮЗӘМ, ЫНА ТҮЗӘМ МӘҢГЕСЕНӘ НИШЛӘРМЕН?" (Х. ТУФАН)
маркасы
ЯНГЫРДАН ЯШЕРЕНЕРГӘ УҢАЙ УРЫН
КАЗАНДАГЫ КҮЛ
БИНА, ӨЙ
БӨРЫНГЫ КЫТАЙДА ТУГАН ӨСТӘЛ УЕНЫ
ИДӘН АСТЫ
"ҮЗЕН ..." (Ф. СӘЛАХОВ)
ЧӘЧӘК
КАМЫР АШЫ (-3)
... КАЕН
ТЫН ГЫНА МОҢ ГЫНА ЖЫР ...
КҮП-...
"ТӘШКӘНДӘ" (Р. МИҢНУЛЛИН)
БАШ АСТЫНДА БАЛЛЫ ...

ТАБЫШМАК-БИЛ АЛЫШМАК

1. Сан-Франциско японча ничек атала?

2. Ни өчен Алла иң беренче дөньяга ир кешене индергән, аннан соң гына хатын-кызны?

3. Рәсәйдә нинди дә булса серләр калды микән?

4. Безнең илдә нинди митинглар була?

5. Үзеңә ошаган машинаны сайлап алу өчен нишләргә кирәк?

6. Офтальмологик диета нәрсә ул?

7. Гомеопатиянең ярдәме кемгә яхшырак тия?

ЖАВАПЛАР

1. Франциско-сан. 2. Үзенең киңәшләре белән кысылып тормасын өчен, хатын-кызны жиргә соңыннан индергән. 3. Сатылмаганнары калган. 4. Рәсәйдә ике төрле митинглар үтә: берсеннән кешеләрне куалар, икенчесенә жыялар. 5. Үзеңә уңайлы эш табу. 6. Ни телисең шуны ашарга мөмкин, ләкин күзләрең белән генә. 7. Сатучыга.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 14 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **"СИНЕҢ ЭЗЛӘР", "САРМАН".**

Беренче булып дөрес жавап жибәрделәр:
Г. ГАРИПОВА (Сарман),
Р. ГАДЕЛШИН (Арча р-ны, Айван ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
М. ХАЛИКОВА (Яңа Чишмә р-ны, Акъяр ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Жиңүчебез – Сарманнан **Галия ГАРИПОВА!**



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

№ 15 2016

Журнал айга бер тапкыр рус һәм татар телләрендә чыга.

«ТАТМЕДИА» АЖ филиалы директоры, баш редактор Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: Ринат АБЗАЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: Александр АЛЕШИН
Үсеш бүлеге мөдире: Павел СТАРОВЕРОВ
Җаваплы секретарь: Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары:
Людмила САФИУЛЛИНА
Артём СУББОТКИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Алмаз ХӘМЗИН
Гузель СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Ләйсән ФӘЛАХОВА

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789 18 май 2015 ел
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.


татмедиа

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

“Флера Гыйззәтуллина шигырьгә әдәбияттан түгел, тормышның үзеннән килде. Ул балачагы, яшьлеге сугыш һәм аннан соңгы елларга туры килгән шагыйрьләр төркеменнән. Вакыйгаларга кытлык юк. Хәл ителергә торган каршылыклар, чынга ашарга ашыккан хыяллар, үзләре өчен көрәш таләп иткән бәхетләр — барысы да күңелдә җыйналган. Шагыйрәнең гражданлык, гуманистик нигезе дә шунда...”

Әхсән БАЯН

Аның шигърияттәге иҗади уңышлары да, өметле яшьләргә һәрвакыт хәерхаһлы булган Сибгат Хәким әйткәнчә, нәкъ менә шул үзе кичергән тормыш вакыйгалары, эше-һөнәре, гаилә анасы, хатын-кыз күңелендә генә туа ала торган уй-хисләре, тойгылары белән тыгыз бәйле.

Безгә — “Чаян”чыларга, күренекле әдипләребез Әхсән Баян һәм Сибгат Хәким мактауларына кушылып, шагыйрәбез Флера Гыйззәтуллинаны олуг юбилее уңаеннан, беркадәр шигырьләрен бастырып, котлыйсыбыз килә. Иҗатыңа — уңышлар, үзеңә озын гомер телибез, хөрмәтле Флера ханым!

ТӘҢРЕМ МИНЕ ТАШЛАМАСЫН

Сусата да, саргайта да Язмыш
Атлаганда моңнар ачышына.
Бер Тәңремә сусап киләм бит мин —
Моң таулары чөеп баш очыма.

Моң аралаш җиргә карлар яуса,
Кар чәчәге булып йомарланам.
Иҗат ирегендә Тәңре Хакы
Югалмаган әле, югалмаган.

Бутамаган әле сабыр башым
Таулар белән карлар аермасын...
...Үзәгемә үткән сусау чирем
Ватаныма гына кабынмасын!

Онытып тауларыма хасланасың, —
Тәңрем генә мине ташламасын!
Хистә тау кичерер юнәлешкә
Тәңре рәхмәтеннән баш аласың.

Соңра сары суккан йөзеңне дә
Кар суында юып агартасың.
Йөзләремнең сарылыгы өчен
Берәүне дә килми каралтасым.

Җаным изгән дошманымны хәтта
Килә бары бәхиллисем генә...
Шуны белгән килеш, һай, таудашым:
— Ник йөзеңне яшермисең? — димә!

ИЛ ӨЧЕН

Шулмы сабак безнең горур башка,
Шулмы сәбәп ургыр хисләргә? —
Сибелә-сибелә чәчләр сирәгәя,
Тулып-түгелеп күңел нечкәрә.

“Хисләнмә, син, сакла үзеңне!” — дип,
Күңелгә шул булмый боерып.
Ихтимал, без һушны җуяр идек,
Сибелүдән торсак тыелып.

Ихтимал, без җирдән китәр идек,
Җир кадерен белми яшәсәк!..
“Туган җир!” — дип, без өзелгән саен,
Җиргә башын ия гөлчәчәк.

Гөлбакчаны кем үстерсә карап,
Шулар күбрәк исни гөл исен.
Сибелүләрем — үрнәк гөлләр өчен,
Сызылуларым минем — ил өчен.

ЯРАТ, ЙӨРӘК!

Ярат, йөрәк!
Яратырга кирәк!
Яратусыз ничек яшәргә?
Ярат, йөрәк, ялкын чәчә-чәчә,
Юллар дәшә ерак сәфәргә.

Ярат, йөрәк!
Мөлдерәмә тулып
Җыр сарылсын нәфис кылларга!
Көйгә салыйм яшьлек елларымны
Күкрәгемдә сагыш-моң барда.

Туйганчы бер күкрәп-тетрәп калыйм:
Күкрәүләрдән, йөрәк, курыкма!
Уйдык-уйдык уй-хисләрем ага
Актарылып явар болытта.

Пешә-пешә җиләкләрем үсә
Уйдык-уйдык уйсу акланда.
Михнәтен дә, нәфрәтен дә җиңдем
Акланнардан илһам тапканда.

Ярат, йөрәк! Сайлап, билгеләп кал
Бар чагында сайлар аланың!..
Ярат, йөрәк, ярат, яратуның
Тапталмаган, саргаймаганын.

ИКЕ ЮЛЛЫКЛАР

• • •

Алтын кибетендә мең йөзек! —
Ияләре йөри ил гизеп.

• • •

Гүзәллеккә хәйран калганда
Мин — унсигез яшьлек һаман да...

• • •

Маңгай сырландырып, чырай сытып,
Якты уйны булмый башта тотып.

• • •

...Үзе ул — шыр шәрә-тумадан;
Кулында шартлардай чемодан.

• • •

...Исән икән әнкәң хәзер дә! —
Исән чакта тиен кадергә!

• • •

Әтидән, әнидән калган мал —
Кыршаусыз тәпәнгә салган бал!

• • •

...һәркемнән йөз грамм “төшереп”
Йөри ул: “Мин бөек кеше!” — дип...

• • •

...Сөйләштек, серләштек бер атна... —
Мәгънәсе кермәде колакка.

• • •

Сүзендә — җәйләрнең хуш исе.
Йөзендә — чатнама кыш төсе.

• • •


Кадерленең гомере эшкә күмелеп үтә,
Кадерсезләр буш гомердән әҗер көтә.

Уйна да, уйла да!




Менә Олимпиада шаулап узды. Истәлеккә кемдәдер медальләр, кемдәдер бәйгенең билгеләре калды. Һәр Олимпиада өчен аерым билге ясала. Китерелгән рәсемнәр буенча уеннар уздырылган шәһәр исемнәрен исеңә төшер.

ТАЛИСМАНОВОРД























Горизонталь буенча: 1. Лондон. 2. Сеул. 3. Афины. 4. Мәскәү. 5. Пекин. 6. Сидней. 7. Барселона. 8. Лос-Анджелес. 9. Атланта.



Яшь рәссамга Питер Брейгельның «Аучылар кар өстендә» дигән картинасының копиясен ясарга заказ биргәннәр. Ул, үзен күрсәтү теләге белән, картинага анда булмаган ун деталь өстәгән. Аларны табыгыз.





ТӨНГЕ МУЗЕЙДА





